XIII «МИНЕМ ГАИЛӘМ ТАРИХЫ – МЕҢЬЕЛЛЫК ВАТАН ТАРИХЫНЫҢ БЕР БИТЕ» ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ ГУМАНИТАР ШӘҖӘРӘ ТӨЗҮ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

**«Гаилә елъязмалары»** номинациясе

# Минем гаиләмнең Россия тарихына керткән өлеше

Хезмәтне башкарды: 39 нчы мәктәпнең 8 Г сыйныфы укучысы Бәйрәмов Искәндәр

Фәнни җитәкче: Максимова Чулпан Афраим кызы югары квалификация категорияле укытучы

Казан, 2020

**АКТУАЛЬЛЕК**

«Үткәннәргә хөрмәт белән карау – гыйлемлелекне кыргыйлыктан аерып тора торган сыйфат», – дип язган үз чорында А. С. Пушкин. Хезмәтнең актуальлеге яшь буынга Россиянең үсеше өчен һәр кешенең керткән өлеше әһәмиятле булуын аңлату зарурлыгы белән билгеләнә. Гаиләнең керткән өлеше зарурлыгын аңлату үсеп килүче буынны гармонияле, патриотик тәрбияләүгә китерә.

**ГИПОТЕЗА:**

Һәр кешенең нинди дә булса өлеше керүе ил өчен мөһим һәм әһәмиятле. Безнең гаилә Россия үсеше өчен күпкырлы әһәмиятле өлеш кертте.

**ПРОЕКТНЫҢ МАКСАТЫ:**

Шәҗәрә агачы, аның үсеш тарихы һәм безнең нәселнең шәхесләре турында мәгълүмат туплауны оештыру. Нәселебез вәкилләренең кешелек эшчәнлегенең нинди өлкәләрендә катнашулары һәм безнең гаиләнең Россия тарихына нинди өлеш кертүен ачыклау өчен тикшерүләр алып бару.

**БУРЫЧЛАР:**

1. Темага кагылышлы материалларны өйрәнү.
2. Эшкәртү һәм тикшерү үткәрү.
3. Җыелган материалларга анализ ясау.
4. Әйтелгән гипотезаны расларга мөмкинлек бирә торган нәтиҗәләр ясау.

**МЕТОДЛАР**

1. ТР архивы белән эш
2. Өйдәге архив белән эш
3. Газета һәм журналлардагы архивлар белән эш
4. Авыллардагы авыл советларындагы архивлар белән эш
5. Шәҗәрә агачын төзү
6. Өлкән буыннардан сораштыру үткәрү
7. Интернет чыганаклары белән эш

**ЭЧТӘЛЕК**

1. Әнием Бәйрәмова Ләйлә Нуровна ягыннан нәселебез тарихы
- ✓ Нәсел турында беренче истәлекләр һәм аның үсеше.
- ✓ Әтисе ягыннан Әхмәдиевлар нәселе (Татарстанның Азнакай районы). Билгеле вәкилләре.
- ✓ Әнисе ягыннан Муратовлар нәселе (Себер). Билгеле вәкилләре.

- ✓ Нәселебез вәкилләре исемнәре белән бәйле тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.
- ✓ Бөек Ватан Сугышына кадәрге чор. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.
- ✓ Нәселебез вәкилләренең Бөек Ватан Сугышында катнашулары. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.
- ✓ Сугыштан соңгы чор.

2. Әтием Бәйрәмов Илшат Рәкыйпь улы ягыннан нәсел тарихы.

- ✓ Әтисе ягыннан – Бәйрәмовлар, Вәлиуллиннар нәселе (Татарстанның Саба районы). Билгеле вәкилләр.
- ✓ Әнисе ягыннан – Нуртдиновлар һәм Матдиновлар нәселе (Свердлау өлкәсе, Урал). Билгеле вәкилләр.
- ✓ Нәселебезнең вәкилләре белән бәйле тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.
- ✓ Бөек Ватан Сугышына кадәрге чор. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.
- ✓ Нәселебез вәкилләренең Бөек Ватан Сугышында катнашулары. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.

3. Сугыштан соңгы чор.
4. Безнең гаиләнең хәзерге тарихы. Хәзерге буыннар.
5. Нәтиҗәләр.
6. Кулланылган чыганаклар исемлеге.

Кайчандыр А.С. Пушкинның фикерләрен укыган идем: “ Үткәннәргә хөрмәт белән карау – гыйлемлелекне кыргыйлыктан аерып тора торган сыйфат” – дип яза ул. Шул вакытта мин уйландым һәм бөек шагыйрьнең безгә нәрсә әйтергә теләгәнен төшендем. “Кыргыйлык” – үз нәселенең традицияләренә, кыйммәтләренә таянмыйча яши торган кешеләргә хас сыйфат. Андый кеше бернигә дә омтылмый, аның максатлары да юк. Андый кешеләрне “соры масса” дип атыйлар. “Кыргыйлык” һаман-һаман хаталар ясаячак, чөнки аларда үткән буыннар тәҗрибәсенә таяну юк. Алар билгеле әйтемдәгечә “үз хаталарында” өйрәнәчәкләр. Ә гаилә традицияләрен белүчеләр һәм аны олылаган кешеләр үз алдында үткәннәрнең мисалын күрәләр, максатны төгәл билгели беләләр һәм шул максатка ирешергә тырышалар. Алар үткәннәрне хөрмәт итәләр, җибәрелгән хаталарны аңлыйлар һәм шулар мисалында эш итәләр. Алар бүтәннәрдән аерылып торалар, аларның “укымышлы” булуы әллә каян күренеп тора. Шушы ук фикерне Петр Иванович Кречетов (1873-1910) та әйтә: «Буыннар арасында гасырлар тирәнлегендә яшеренгән рухи бәйләнеш урнашмый торып, бөек халык өчен кирәк булган тарихи үзаң килмәячәк. (Орлов губерниясен тасвирлау өчен материаллар. Рига, 1905)

Бервакыт без бабам Нур Әхмәдиев белән сөйләшкән идек. Ул миңа үзенең “Аманәт” шигырен укыды. Әлеге шигырендә ул безгә, үзеннән соң килгән буынга эндәшә:

«Мин калдырам сиңа рух ныклыгы,
Моңнар ташып торган телемне.
Шушыларны кабул итсәң генә,
Тыныч каршыларнмын үлемне.

Мирасымда – тапланмаган намус,
Йөз сыналганиман калдырам.
Җиде буын бабам бәхиллеге
Сиңа кала бар да, ал, олан!»

(Нур Әхмәдиев, “Күзгә-күз” шигырьләр җыентыгы, 87 бит)

Әлеге шигырь юллары минем күңелемә үтеп керде. Һәм мин “Минем шәҗәрәм” конкурсы үткәрелүе турында ишеткәч, үземнең әби-бабаларым турында күбрәк беләсем килүен аңладым. Алар кем булган, нәрсә белән янып яшәгән, гаилә традицияләре нинди булган, безнең шәҗәрә агачының тамырлары каян үсеш алган?

Мин төрле чыганаклардан мәгълүмат эзли башладым. Болар Азнакай районы Әсәй авыл советы архив материаллары, Курган өлкәсе Шатрау районы Кызылбай (Тагыл) авылы советы архив материаллары, гаилә архивы материалларыннан гыйбарәт иде. Алар арасында Гөлсинә Теплованың мәгълүматлар туплап язылган “Буыннар хәтере. Шаһиевлар һәм Әхмәдиевлар (XIX гасыр ахыры – XXI гасыр башы) нәселе истәлекләре” китабы да бар. Бабам Нур Әхмәдиев үтенече буенча тарихчы Дамир Гарифуллин төзегән шәҗәрә зур ярдәм итте. Моңа кадәр барлыкларын әти-әнидән һәм өлкән буыннан ишетеп кенә белгән ерак туганнар белән дә бик күп сөйләшүләр алып бардым. Бу бик кызыклы һәм мавыктыргыч шөгыль булып чыкты. Материалларны туплап, гомумиләштергәч, тулы ышаныч белән әйтә алам: мин үз нәселем һәм аның үсеше белән горурланам!

Менә мин нәрсәләр белдем. Минем нәселем Татарстанның Азнакай һәм Саба районнарын, Себерне һәм Уралны берләштергән. 14 (!) буыннан торган шәҗәрәне ачыклый алдым.

## 1. ӘНИЕМ БӘЙРӘМОВА ЛӘЙЛӘ НУРОВНА ЯГЫННАН НӘСЕЛ ТАРИХЫ

## ӘТИСЕ ЯГЫННАН – ӘХМӘДИЕВЛАР НӘСЕЛЕ (ТАТАРСТАН, АЗНАКАЙ РАЙОНЫ).

- ✓ **Нәсел һәм аның үсеше турында беренче истәлекләр.**
- ✓ **Билгеле вәкилләре.**

✓ **Нәсел вәкилләре исемнәре белән бәйле тарихи вакыйгалар турында кыскача тасвирлау.**

✓ **Бөек Ватан Сугышына кадәрге чор. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.**

✓ **Нәселебез вәкилләренең Бөек Ватан Сугышында катнашуы. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.**

✓ **Сугыштан соңгы чор.**

Әни ягыннан нәселебезнең иң борынгы вәкиле Килдем исемле бабам була. Аның Азнакай районы Әсәй авылында яши башлавы якынча 1600 ел дип билгеләнә. Аның исеме, ул вакытта кабул ителгәнчә, аның әлеге авылга килеп чыгуы белән бәйле рәвештә барлыкка килгән. Минем әнием бабамның бабасы Гарифтан (Мөхәммәтгариф), безнең нәселнең беренче вәкиләре Башкортстан якларыннан күчеп килгәннәр, дип ишеткән була. Иң борынгы бабаларымның исемнәре сакланып калган: Килдем, Ураз, Күчем, Түтек, Әптек, Имәнгол, Айдагол. Төрле төзүчеләрдән шәҗәрәнең берничә варианты бар.




*Әхмәдиевлар нәселе шәҗәрәсе (төзүче Искәндәр Бәйрәмов). Кушымтаны карагыз*




*Әхмәдиевлар нәселе шәҗәрәсе (төзүче Гөлсинә Теплова). Кушымтаны карагыз*






*Әхмәдиевлар нәселе шәҗәрәсе (төзүче тарихчы Дамир Гарифуллин).*

Әхмәдиевлар нәселенең беренче вәкиле архив документлары буенча Төхвәтулла (1830-1861) булуы ачыкланды. Аның улы – Әхмәди – Гарифә Йосыф кызына өйләнә. Әлеге никахтан 6 бала туган. Әхмәди 1921 елда вафат булган. Әхмәдинең нәсел дәвамчысы – минем бабам Мөхәммәд-Харис.Абыйсы Хәмзә вафат булганнан соң ул аның ике улы – Нуретдин һәм Хәертдин белән тол калган хатыны Галиябануга өйләнә. Аларның тагын уртак 6 баласы туа: Гариф, Гайшә, Шәриф, Латиф, Рәхимә, Билал. Билал бала вакытта ук вафат була. Бу ярлылык һәм ачлык вакытлары, Беренче Бөтендөнья сугышы еллары була. 1915 елда Гарифның әтисе Харис вафат була. 1921 елгы ачлыкны Әхмәди

бабай, Шәриф һәм Латиф кичерә алмыйлар. Рәхимә чәчәк авыруыннан сукырая һәм озакламый вафат була.

**Минем бабамның әтисе – Гариф (метрикә буенча Мөхәммәтгариф, (1904-2004)**

Ул 1904 елның 28 маенда Азнакай районы Әсән авылында туа. Бик сәләтле була, белемгә омтыла, Мәчет яны мәдрәсәсенең 4 сыйныфын тәмамлый. 2004 елның 18 гыйнварында вафат була. Бөек Ватан сугышында катнашкан.

### Әхмәдиевлар фамилиясе тарихы

Минем бабамның әтисе Мөхәммәтгариф (Гариф бабай) 17 яшьлек вакытта әтисез кала. Алар бабасы Әхмәди белән яшиләр. Фамилияне дә шул рәвешле ала. Фамилияне язганда сораганнар: “Кемнеке буласың?”, ул: “Әхмәди”, – дип җавап биргән. Шулай итеп, әнием ягыннан нәселем Әхмәдиевлар булып киткән.





*Гарифның гарәп һәм рус телләрендәге туу турында таныклыгы*

### Өйләнү

1929 елда бабаемның әтисе бабаемның әнисе Яшәр авылы мулласы кызы Бәдриҗамалга өйләнә. 1929 елгы никах таныклыгы сакланып калган. Әлеге никахтан 9 бала дөньяга килгән. Аларның өчесе (Марсель, Илгизәр, Флүрә) кече яшьтә үк төрле авырулардан вафат булалар. Алтысы (Фәния 1930, Лена 1938, Сиринә 1941, Нур 1946, Нурия 1959, Галия 1953) исән калалар, сәламәт булып үсәләр һәм, вакыты җиткәч, гаиләләр коралар.

*Свидетельство о рождении Бадриямал, выданное в 1933*





*Слева направо стоят: Лена, Нур, Сирина*

*Сидят: Бадриямал, Нурия*

*1953*



*Авыл советы депутаты таныклыгы.* 1939 ел.

## Совет власте. Сугышка кадәрге чор.

Бабамның әтисе сугышка кадәр 1920-1930 елларда авыл советы секретаре, сельпо хисапчысы, халык һәм мал-туар баш санын алучы, агитатор, ликбез җитәкчесе, сельпода ревизия комиссиясе әгъзасы булып эшли. Азнакай районы Әсәй авыл советы депутаты була.

## Хәрби юл

Бабамның әтисенең хәрби билеты сакланып калган.

Бабамның әтисе 1941 елның 26 августында Азнакай хәрби комиссариаты тарафыннан сугышка чакырыла. Шул көннән башлап 1942 нче елның 7 нче июненә кадәр 386 нчы укчы полк составында сугышта катнаша. Аннан соң 7 нче июльгә кадәр 1263 нче укчы полк составында минометчы була.







Шуннан камалышка эләгә. Камалыштан котылып, Гариф бабай 283 номерлы тикшерү-фильтр лагерена эләгә, аннан Сталиногорск шәһәрендәге 388 номерлы хәрби әсирләр лагерена эләгә. Шахтада хезмәт куя. Каты җәрәхәтләнгәннән соң аны Мәскәү янындагы Мардеса районына җибәрәләр. Анда ул агач кисүдә эшли. 1946 елның февралендә генә өенә әйләнеп кайта.

## Тыныч вакыт

Сугыш беткәннән соң колхозда җитәкче вазифаларны башкара. 80 яшькә кадәр колхозда эшләвен дәвам итә.

Кызы Нурия истәлекләреннән:

*«Безнең әти Гариф егерменче гасырның барлык әһәмиятле вакыйгаларының катнашучысы һәм шаһите була: 1917 елгы социалистик революция, гражданнар сугышы, 1921-22 елгы ачлык, коллективлаштыру, 1941-1945 елгы Бөек Ватан Сугышы. Тормышның барлык авырлыкларына карамастан, ул үзенең кешелек сыйфатларын югалтмаган: ул игелекле, шат күңелле иде, шаяртырга яратты. 1921 елның ачлык вакытында кышын аны үлүчеләр исемлегенә керткәннәр, ләкин ул бирешмәгән, ишегалдында яшел үлән чыкканын көткән һәм үрмәләп шуны җыйган, инде йөрергә хәле калмаган булган. Ул тормышны яратучан иде, белемгә омтылды.Әлеге сыйфатын ул үз балаларына да тапшырырга тырышты.*

*Балачактагы бик җылы бер хатирәне сөйлисем килә: без кечкенә вакытта караватлар юк иде, без бөтен гаиләбез белән (әти, әни һәм барлык балалар) бер стенадан икенче стенага кадәр сузылган, идәннән 60 см биеклектәге агач сәкедә йоклый идек. Кайвакыт, әти бик арымаган көннәрдә йоклар алдыннан, торналар турында үзе уйлап чыгарган әкиятне сөйли иде. Имеш, торналар таң алдыннан безнең ишегалдына килеп куналар икән дә, әтине аркаларына утыртып, ерак-еракка – чит илләргә очыртып алып китәләр икән. Без, йокларга онытып, әтинең сөйләгәнен авызыбызны ачып тыңлап ята идек. Шул рәвешле ул үзенең сәяхәт итү турындагы хыялларын безгә тапшыра иде. Без аның әлеге хыялларын тормышка ашырдык, дип әйтә алам. Әти безнең белән бик кызыклы бер уен уйный иде, ул безгә рус теле дәресләре үткәрә иде: татар сүзләренә “-ски” кушымчасы ялгап, “рус телендә шулай сөйләшәләр” дип әйтә иде. Без күздән яшьләр чыкканчы көлә идек.*





Ул Ватан өчен сугышкан, аны яраткан.

Гариф Харис улы 2004 нче елның 18 гыйнварында, 100 яшь тулырга дүрт ярым ай вакыт калгач вафат була. Азнакай районы Әсәй авылы зиратында күмелгән.

Аның яраткан җыры “Кошлар кебек”:

“Һаваларда очкан кошкайларның
Каурыйлары коела җилләргә.
Туфрагына алтын чәчсәләр дә,
Җитми икән туган илләргә.




*Гариф бабай токымы (Искәндәр Бәйрәмов төзегән шәҗәрә).*

**Фазыл Фазлыйәхмәтович Шагиев (23.12.1925 – 03.04.2015)**

Гарифның өлкән кызы Фәниянең тормыш иптәше Фазыл Шагиев та Бөек Ватан Сугышында катнаша. Аны 1944 елның гыйнварында сугышка алалар. Алты ай хәрби әзерлек курслары үткәннән соң ул Беренче Белоруссия фронтына эләгә. Ул кечерәк буйлы, ләкин ныклы гәүдәле була – аңа егерме килограммлы ПТРны (танкка каршы корал) ышанып тапшыралар.

Фазыл абый безгә үзләренең батальоннары белән Днепр буенда каһарманнарча көрәшкән көннәре турында сөйли иде. Бу төнлә була, фашистлар булган барлык коралларыннан ут ача. Бер кул белән ишеп йөзәргә туры килә аларга, икенче кулларында сугышчыларның мылтыклары була. Днепрның уртасына җиткәч, Фазыл ташландык агач сал күреп ала. Һәм, әлеге салга ышыкланып, ул елганың икенче ярына йөзеп чыгып җитә ала. Яр кыя шикелле текә була, шул аны саклап кала да инде.

Төн буена, табигый ышыклану урыннарын кулланып, Фазыл фашистлар белән атышып чыга. Ярдәм иртә белән генә килеп җитә, һәм алар барысы бергә фашистларны җиңеп чыга һәм көн уртасына совет гаскәрләре Днепрның Төньяк ярын дашманнардан азат итә. Икенче көнгә Фазыл теге төндә аларның батальонынннан Днепрны ике генә сугышчы кичеп чыга

алганлыгы турында белеп ала. Ут яңгыры астында Днепрны кичеп чыгуы өчен Фазыл Шаһиев “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнә.



*Фазыл һәм Фәния Шагиевлар*
*50 ел бергә. 1999 ел.*

*1944 елның августында Днепрны азат итү сугышларында аның сул кулы яралана. Сөякләре чәрдәкләнеп, кулы сеңердә асылынып кала. Госпитальләрдә озак дәваланулар башлана, башта кыр госпиталендә, аннан ай буена Брянск шәһәрендә санбатта, дүрт ай Омск шәһәрендәге госпитальдә дәвалана.Хирурглар аның кулын кисәргә ниятләгән булалар, ләкин ул аларны үгетли ала, бәхеткә, күп хирурглар хатын-кыз була, сугыш ахырына якынлашып килә. Фазылга кулын саклап калу буенча эксперименталь операция ясыйлар. Операция уңышлы чыга. Кулы кыскарак һәм кәкре булып калса да, ул эшли торган була, бармаклары бөгелә. Соңыннан аны студентлар каршында тере экспонат буларак, Омск шәһәренең медицина институтына профессорлар лекцияләренә чакыра торган булалар.*

*Фазыл гомере буе колхозда бригадир булып эшли, авылдашларына мөгамәләсе аркасында аларның хөрмәтен яулый, Совет хөкүмәтенең күп төрле мактау грамоталары, ә Татарстан күләмендә иң күп карабодай уңышы җыеп алган өчен Хөрмәт билгесе ордены белән бүләкләнә.* [4].

**Минем бабам – Нур Гариф улы (1946 елда туган)**

Гаиләдә бердәнбер малай. 1946 нчы елның 14 нче декабрендә Азнакай районы Әсәй авылында дөньяга килә.



Ул күренекле шагыйрь һәм язучы булып таныла, Бөтендөнья ПЕН клуб (ингл. *PEN International*) – бөтен дөньяның һөнәри язучыларын, шагыйрьләрен, журналистларын берләштергән халыкара хокук саклау оешмасы әгъзасы. 1984 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе.

Югары белемне ул Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында ала. Үзенең беренче шигырен 4 нче сыйныфта укыганда яза.

Сарлы авылында укытучы, ВЛКСМның Азнакай районы комитетында икенче секретарь булып эшли. 1970 нче елдан Нур Әхмәдиев төрле газета-журналларда басыла башлый. ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген җитәкли. “Татнефть» ААҖнең “Хәзинә” корпоратив газетасында 15 ел җитәкчелек итә.

Балалар һәм зурлар өчен 25 китап авторы. Аның каләме астыннан “Абага чәчәге”, "Ак бишегем", "Амбирак", "Атларым, колыннарым", "Мөнирстан" һәм башка китаплар чыга.

Аның бөтен иҗаты лирик юнәлешле һәм Җиргә, Татарстанда яшәүче гади кешеләргә мәхәббәт белән сугарылган.














Аның 130дан артык шигыренә җыр язылган. Сажидә Сөләйманова, Рафаэль Төхфәтуллин һәм Мәхмүт Хәсәнов исемендәге әдәби премияләр, “Татнефть” җәмгыятенең “Рухият” рухи яңарыш фонды премиясе лауреаты.



*1996 елда Г.Камал театры сәхнәсендә 50 яшьлек юбилей бәйрәмендә.*

Бинем бабаем – менә дигән гаилә башлыгы. Һәр шагыйрьнең илһамчысы була. Аның гомерлек илһамчысы – минем әбием – Әхмәдиева (Сәфәрова) Венера Газизҗан кызы.

**1. ӘНИ (Бәйрәмова Ләйлә Нуровна) ЯГЫННАН НӘСЕЛ ТАРИХЫ**

✓ **ӘНИСЕ ЯГЫННАН – МУРАТОВЛАР ҺӘМ КАСЫЙМОВЛАР (СЕБЕР) НӘСЕЛЕ.**

## БИЛГЕЛЕ ВӘКИЛЛӘРЕ

**Минем әбием – Әхмәдиева (Сәфәрова) Венера Газизҗан кызы, (1945 елда туган)**

Әлеге гадәти булмаган хатын-кыз Себердә, Курган өлкәсенең Шатрау районы Тагыл авылында туган.

Бабай бик күп шигырьләрен аңа багышлаган һәм аны “Венера Тагыллы” дип йөртә. Ул “Сәламәтлек саклау отличнигы”, медицина клиникасы җитәкчесе, әле хәзер дә эшләвен дәвам итә.



“33” ел үткән дә киткән... Туйлар узгач, хатыны Венера белән. Азнакай, 1970 ел, июнь.



Венера һәм Нур Әхмәдиевләр кызлары Ләйлә белән. Азнакай, 1972-1973 еллар.

Әлеге никахтан ике бала дөньяга килә: минем әнием – Бәйрәмова (Әхмәдиева) Ләйлә Нур кызы (1971 елда туган) һәм энесе – Әхмәдиев Равил Нур улы (1976 елда туган).

**Билгеле вәкилләре**

Әнисе ягыннан – Муратовлар (Себер) нәселенең билгеле булган беренче вәкиле Кальбиҗамал (1888 елда туган) һәм Әбүгәрәй (1937 елда репрессияләнә).






Сулдан уңга: карт картинәй әбинең апасы Фәриха апа, карт картинәй әби Кальбиҗамал, картинәй әби Зөләйха , 1987 ел.

## НӘСЕЛ ВӘКИЛЛӘРЕ БЕЛӘН БӘЙЛЕ ТАРИХИ ВАКЫЙГАЛАРНЫ КЫСКАЧА ТАСВИРЛАУ.

**Бөек Ватан сугышына кадәрге чор. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау**

### Җәлил һәм Әбелгәрәй бабайларның һәлак булуы

Кальбиҗамал әби 1916 елда Муратов Җәлилгә кияүгә чыга.1917 елда аларның уллары Мәҗит туа. 1922 елда Җәлил авылдашы Назыйров Хәйрулла кулыннан һәлак була. Назыров кача һәм җинаять җаваплылыгыннан качып котыла. Җәлилнең олы абыйсы Әбелгәрәй һәлак булган энесенең тол хатынын кечкенә сабые белән ташлап калдырмас өчен, аны икенче хатын итеп ала. Шул никахтан минем картинәй әби Зөләйха һәм аның сеңлесе Фәриха дөньяга килә. Әбелгәрәй большевик була һәм 2 ел Кызыл Армия сафларында сугышта катнаша.



Әмма Назыровлар нәселе Касыймовлар нәселен эзәрлекләвен дәвам итә. 1937 елның июлендә, Назыров әләкләве буенча, троцкизмда гаепләп, Әбелгәрәйне печән чапкан җирдән алып китәләр. Аның эзе шулай югала. Аны рудникларга җибәргәннәр дигән имеш-мимешләр йөри. Соңрак, 20нче гасырның 60нчы елларында картинәй әби архивлардан әтисенең эзләрен эзли. Ләкин берни дә тапмый. Курган өлкәсендә Шадринда булганда ул туган якны өйрәнү музеена керә. Һәм диварга эленгән элмә тактада Касыймов Әбелгәрәй исеме язылганлыгын күрә. Аны шул ук 1937 елда атып үтергәннәр. Троцкизмда гаепләү күрсәтмәләрен һаман шул Назыров Хәйрулла биргән.

Назыровлар нәселе әле моның белән дә тынычланмый. Инде советлар чорында Хәйрулланың улы Зариф картинәй әби Зөләйханың йорт-җирләренең бер өлешен үзләштерә. Ниндидер аңлашылмый торган көнләшү Зариф Назыровның үз баласына исем бирүдә дә чагыла. Безнең нәселдә бер малай туа, һәм аңа Арыслан дигән исем бирәләр. Зариф әлеге яңалыкны ишеткәч, авыл советына бара һәм: “Алар малайларына Арыслан дип исем кушканнар. Болай булгач, мин үз улымны Фил дип атармын”, - ди. Авыл советы эшчеләре баланың язмышын бозмаска үгетлиләр. Ләкин ул исемнең беренче хәрефен үзгәртергә генә риза була, улына Вил дигән исем бирә.

Назыровлар нәселенең тарихы хәерле тәмамланмый. 21 гасыр башында Вил үзенең хатынын үтерә. Ә күпмедер вакыттан соң ул үз өендә янып үлә. Аның бер улы (минем әниемнең яшьтәше) ауга баргач үз кулына ата һәм гарип кала.

Әбелгәрәй Муратовларда бөтенләй башка тарих күзәтелә. Алар Бөек Ватан Сугышы елларында да, сугыштан соң да үзләрен яхшы яктан гына күрсәтәләр.

**«Троцкист кызы» Муратова Зөләйха Әбүгәрәй кызы**

1937 ел вакыйгаларыннан соң, Әбелгәрәйне НКВД алып киткәннән соң, картинәй әбине “троцкист кызы” буларак бик күп еллар эзәрлеклиләр. Аңа авылдан китәргә һәм фамилиясен Хуҗинага алмаштырырга туры килә.

Сулдан уңга: Зөләйха әбинең апасы Фәриха апа һәм Зөләйха әби. Аскы рәттә: минем әбием Венера, Әминә, Мөнәвәрә, Рәхимҗан, 1951 ел.


СВИДЕТЕЛЬСТВО О РОЖДЕНИИ
Гр. Хуснина (фамилия,
Замиха Абдулгареевна имя, отчество)
родился (лась) 1/XI 1926 г. (прописью и цифрами год,
Первого ноября месяц и число)
Тысяча девятьсот
двадцать шестого года
Место рождения ребенка: город, селение
с. Кызылбай. Мехонский
район Курганская область, край,
республика РСФСР
чем в книге записей актов гражданского состояния
о рождении 1926 года ноября месяца
4 числа произведена соответствующая запись
№ 61.


РОДИТЕЛИ:
Отец Хуснин (фамилия,
Абдулгарей имя, отчество)
национальность татарин
Мать Хуснина (фамилия,
Калбизомал имя, отчество)
национальность татарка
Место регистрации Кызылбаевский с/с (наименование и
Мехонского р-на местонахождение бюро ЗАГС)
Курганской обл.
Дата выдачи 29. декабря 1952 г.
М. П.
ШГ № 463670

Соңрак ул Сәфәров Газизҗанга кияүгә чыга һәм аларның кызлары – минем әбием Венера туа. Кызганычка каршы, әбиемнең әнисе гаиләсе белән кушыла алмый һәм әбиемнең әнисе Зөләйха Кучкильдин Рәхимҗан Закир улына кияүгә чыга. Ул 30 елдан артык Кызылбай авыл советында секретарь булып эшли. Аның ире Кучкильдин Рәхимҗан Закир улы РФнең Атказанган агрономы була. “Очкын” колхозында 30 ел агроном булып эшли.

## НӘСЕЛЕБЕЗ ВӘКИЛЛӘРЕНЕҢ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА КАТНАШУЫ. ТАРИХИ ВАКЫЙГАЛАРНЫ КЫСКАЧА ТАСВИРЛАУ

**Муратов Мәҗит Җәлил улы, 1917 елда туган.**

*Кальбиҗамал һәм Җәлилнең улы Мәҗит Бөек Ватан сугышы катнашучысы була.*

*Ул 1938 елның 7 августында хәрби хезмәткә алына. 94нче артиллерия полкына эләгә, шуның составында 1941 елның 5 сентябреннән 1943 елның 9 сентябренә кадәр танкка каршы корал командиры вазифасында өлкән сержант званиесында сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша.*

*Кырымны азат итә. Соңрак 116нчы Милитополь ныгытылган районында наводчик булып сугышта катнаша. 1945нче елның 16 октябрендә запаска күчерелә. Кенинсбергны азат итүдә сугышчан заданиены бик яхшы үтәве өчен 3нче дәрәҗәле дан ордены, 2нче дәрәҗәле Ватан сугышы ордены, белән бүләкләнә, “Мәскәүне саклаган өчен”, “Сталинградны саклаган өчен”, “Германияне җиңгән өчен” медальләре, Җиңү көне юбилее медальләренә ия була. Милитополь шәһәрен азат итүдәге бик яхшы сугышчан хәрәкәтләре өчен Югары Башкомандачы иптәш Сталинның рәхмәтенә ирешә.*

*Мәҗит Җәлил улы 1998 елда вафат була.*

Мәгълүматлар Курган өлкәсе Шатрау районы Кызылбай авыл советының Хәтер китабыннан алынды.

Нәселдә, Мәҗит Җәлил улының Советлар Союзы герое исемен алуы турында легенда бар. Бүләкләү кәгазе килгәндә Мәҗит госпитальдә яткан һәм бүләкләү кәгазен госпитальнең канцеляриясенә вакытлыча урнаштырып торалар. Мәҗит госпитальдән чыккан вакытка әлеге бүләкләү кәгазе югалган була, ә Мәҗит аны яңадан торгызу артыннан йөрмәгән, фронтка сугышка китеп барган. Моның шулаймы, юкмы икәнлеген белү өчен архивларда эшне

дәвам итү сорала. Минем күңел түрендә безнең нәселдә Советлар Союзы герое бар, дигән ышаныч яши!

Әбелгәрәйнең беренче хатыны белән никахыннан ике кыз дөньяга килә: Һава (24.05.1926) (аңа хәзер 93 яшь) һәм Шәүкия (01.12.19-18.032012).

**Муратова Һава Әбелгәрәй кызы**

Тыл хезмәткәре була. Сугыш вакытында колхозда фермада эшли, бозау караучы, сыер савучы була. Хәзерге вакытта ул исән, шушы көннәрдә Җиңүнең 75 еллыгына юбилей медале белән бүләкләнде.

**Муратова Шәүкия Әбелгәрәй кызы**

Рәфикъ Касыймовка кияүгә чыга. Шуннан икенче тармак – Касыймовлар тармагы китә.



**Касимов Рәфикъ Мөхәммәт улы (25.10.1917 – 23.05.2001)**

Касимов Рәфикъ Мөхәммәт улы Курган өлкәсе Шадрин районы Байрак авылында туа.

Байрак мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1933 елда Төмән Медицина техникумына укырга керә һәм аны 1935 елда тәмамлый. 1935 елдан алып 1939 елга кадәр Курган өлкәсе Шадрин районы Байрак авылында фельдшер булып эшли.

1939 елда Кызыл Армия сафларына чакырыла, Забайкалье һәм Ерак Көнчыгыш хәрби округларында төрле медицина вазифаларында хезмәт итә. Хезмәтен 1948 нче елда НКВД частендә (Хабаровск шәһәре) медицина хезмәте җитәкчесе вазифасында медицина хезмәте өлкән лейтенанты званиесендә тәмамлый.

Ватан Бүләкләре: Кызыл йолдыз ордены; I дәрәҗә Ватан сугышы ордены; II дәрәҗә Ватан сугышы ордены; “Сугышчан хезмәтләре өчен” медале, “Германияне җиңгән өчен” медале, “Японияне җиңгән өчен” медале, “1941-1945 фронтовигына” юбилей Ордены, “Георгий Жуков”, “1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышының 20, 30, 40, 50, 65 еллыгы”юбилей медальләре. Яралы сугышчыларга медицина ярдәме күрсәтүдә бик яхшы сугышчан хәрәкәтләре өчен ике тапкыр генералиссимус Сталинның рәхмәтенә ия була.

Тыныч елларда 1948 елдан алып 1967 елга кадәр Курган өлкәсе Шадрин районы Байрак (Терсүк) авылында фельдшер булып эшли. 1967 елдан алып 1977 елга кадәр Курган өлкәсе Шадрин районы Байрак авыл советы председателе булып эшли. Курган өлкәсе Шадрин районы Байрак авылы зиратында күмелгән.

Улы да аның эзеннән киткән.

**Касимов Арыслан  Рәфикъ улы**



1965нче елда Атчин хәрби авиация-техник училищесына укырга керә, 1975нче елда Профессор Н,Е.Жуков исемендәге Хәрби-һава инженериясе академиясен тәмамлый. Аның ирешкән уңышлары исемлеге бик зур. Озак еллар Россиянең ФПС Курган хәрби институтының Оча торган аппаратларның авиацион кораллану комплекслары эксплуатациясе кафедрасы җитәкчесе булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда. Төмән шәһәрендә яши.

## 2. ӘТИЕМ БӘЙРӘМОВ ИЛШАТ РӘКЫЙПЬ УЛЫ ЯГЫННАН НӘСЕЛ ТАРИХЫ.

✓ **ӘТИСЕ ЯГЫННАН – БӘЙРӘМОВЛАР, ВӘЛИУЛЛИННАР (ТАТАРСТАН, САБА РАЙОНЫ). БИЛГЕЛЕ ВӘКИЛЛӘРЕ.**




*Минем әтием Илшат Бәйрәмов ягыннан шәҗәрә (төзүчесе Искәндәр Бәйрәмов). Кушымтаны карагыз.*

## НӘСЕЛ ҺӘМ АНЫҢ ҮСЕШЕ ТУРЫНДА БЕРЕНЧЕ ИСТӘЛЕКЛӘР.

### Бәйрәмовлар фамилиясе тарихы

Әтием ягыннан нәсел турында мәгълүматлар күп түгел. Әтиемнең бабалары Вәлиша, Вәлиулла, Бәйрәмгали. Кыз туганнарым һәм ир туганнарымның бер өлеше Вәлиуллин фамилиясен йөртәләр ( Вәлиулла бабай фамилиясе буенча). Җиде баланың өчесенә генә Бәйрәмов фамилиясе (әтисе Бәйрәмгали исеме буенча) бирелә: Нәсимә, минем бабам Рәкыйпь һәм Рәхмәтулла.



*Бәйрәмовлар һәм Вәлиуллиннар нәселенең беренче билгеле вәкиле ягыннан шәҗәрә (төзүчесе Искәндәр Бәйрәмов). Кушымтаны карагыз.*

## БИЛГЕЛЕ ВӘКИЛЛӘРЕ:

**Бабаем – Бәйрәмов Рәкыйпь Бәйрәм улы (1941 елда туган)**



Минем әтием ягыннан бабаем – Бәйрәмов Рәкыйпь Бәйрәм улы 1941нче елның 17нче августында Татарстанның Саба районы Түбән Отар авылында туган. 1964нче елда Казан химия-технология институтын тәмамлап, анда органик химия укыта. 1968 елда ул “3-фениларсин белән галогенобутил эремәләренең үзара йогынты ясау механизмы һәм кинетикасын өйрәнү” темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Ул вакытта беренче тапкыр мышьякның галогенобутиллар белән кушылмасын табалар. Әлеге реакциянең матдәләре – потенциаль фунгицид һәм инсектицидлар. Әлеге ачыш авыл хуҗалыгы өлкәсендә үсемлекләрне чүп үләннәреннән һәм корткычлардан арындыруда киң кулланылыш тапты. Үзгәртеп кору елларында бабай шәхси фәнни предприятиесен булдыра һәм озак еллар анда җитәкчелек итә. Хәзерге вакытта бабай лаеклы ялда.




Кызганычка каршы, борынгы әби-бабайлар турында артык күп белә алмадык, чөнки әтисе Бәйрәмгали вафат булганда бабай бик кечкенә була әле. Бабайның апасы Рәшидә (1930 елда туган) сөйләве буенча, Бәйрәмгали һәм аның Госман, Хикмәтулла исемле ир туганнары бик яхшы тимерче, механик булганнар. Әлеге юнәлештә тикшеренүләрне тирәнтенрәк алып барырга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдем.

Әлеге нәселдән бик күп укытучылар чыккан, медицина һәм фән өлкәсендә хезмәт куючылар да бар.

## 2. ӘТИЕМ БӘЙРӘМОВ ИЛШАТ РӘКЫЙПЬ УЛЫ ЯГЫННАН НӘСЕЛ ТАРИХЫ.

✓ **ӘНИСЕ ЯГЫННАН – НУРТДИНОВЛАР-НУРДИНОВЛАР ҺӘМ МАТДИНОВЛАР (Свердлау өлкәсе, УРАЛ). БИЛГЕЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕ**

✓ **Нәсел вәкилләре исеме белән бәйле тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.**

✓ **Бөек Ватан Сугышы елларына кадәрге чор. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.**

✓ **Нәсел вәкилләренең Бөек Ватан Сугышында катнашулары. Тарихи вакыйгаларны кыскача тасвирлау.**

✓ **Сугыштан соңгы чор.**

**Нурдинов һәм Матдинов фамилияләренең килеп чыгышы.**

Әтиемнең әнисе ягыннан безнең нәселнең беренче вәкиле Матдин була, якынча 1830-1840 елларда туган. Аның улы Нуртдин Матдинов һәм хатыны Гарифә Матдиновадан (1862-1941) Нуртдиновлар нәселе тармакланып киткән. Матдин һәм Нуртдин Матдинов турында исемнәреннән башка берни дә билгеле түгел. Ә Гарифә Матдинованың үлеме турында мәгълүматлар билгеле. Ул 1941 елның февраль аенда кызы яшәгән авылдан үзенең туган авылы Кичкергә кайтканда, буранда кырда адашып туңып үлә. Әлеге никахтан 8 бала дөньяга килә: Шәрип, Халидә, Фәидә, Шәмсекамәр, **Хафиз**, Вәсби, Җиһангир, Галимҗан.

Нуртдиновлар фамилиясе Нуртдин Матдиновтан киткән. Ул вакытта гомуми гыйлемлелек бик түбән була. Авыл советында фамилияләрне язганда беренче өч улы Хафиз, Җиһангир һәм Галимҗан фамилияләре “т” хәрефен төшереп калдырып, Нурдинов дип языла, ә калган балаларына бабалары фамилиясе бирелә. Шулай итеп, ир һәм кыз туганнары арасында Матдиновлар була: Шәрип, Халидә, Фәидә, Шәмсекамәр, Вәсби. (Әбием Бәйрәмова Ә.Х. истәлекләреннән.)



*Матдин (Нурдиновларның иң беренче вәкиле) токымы. Искәндәр Бәйрәмов төзегән шәҗәрә.*

**Бабамның әнисе – Кәримә Хәбибуллина (1943нче елда үлгән)**



Минем бабаемның әнисе – Хафизның бабайның беренче хатыны шәһәр зыялылары гаиләсендә туып үсә. Аларның никахыннан ике бала дөньяга килә: Сталик (1937 елда туган) һәм Әнисә (1938 елда туган). Кызганычка каршы, Кәримә әби сугыш елларында (1943 елда) бик яшьли вафат була. Ул вакытта Әнисә әбигә 5 яшь кенә була.

Әбием миңа бер вакыйга сөйләде, әлеге вакыйга мине бик тетрәндерде.

*Кәримә әби крючок белән бик матур итеп күлмәк якалары бәйли торган була. Иң матурын ул кызы Әнисәгә дип бәйли. Хафиз бабай хәрби состав белән фронтка китеп бара, өйдә ашарга берни дә булмый. Әнисе Әнисәдән күлмәк якасын сатарга сорый һәм аңа яңаны, тагын да матурракны бәйләп бирергә вәгъдә итә. Әнисә әби риза була. Шулай итеп, аның әнисе базарга барып яканы сата һәм гаиләгә ашарга ризык алып кайта. Әмма Кәримә әби кызына вәгъдә иткән яканы бәйләп өлгерә алмый, каты авырып китә һәм озакламый вафат була. Кечкенә кызның хәтеренә әнисен югалтуның ачы кайгысы иң кадерле нәрсәсен, әнисе тарафыннан аңа дип бәйләнгән ак яканы югалту буларак кереп кала...(Әбием Бәйрәмова Ә.Х. истәлекләреннән.)*

1943нче елда Кәримәнең вакытсыз үлеменнән соң, фронттан вакытлыча гына кайткан Хафиз Нуртдинов унҗиде яшьлек кызга, Рәйханага өйләнә (Хафизның икенче хатыны). Берничә көннән соң ул кабат фронтка китеп бара. Калган гомерләрен алар бергә үткәрәләр, Хафиз бабай аны бик ярата. Әлеге никахтан тагын ике кызлары туа: Әлфия (22.08. 1944 елда туган) һәм Әлфирә (26.07. 1949 елда туган).

**Әтием ягыннан әбиемнең әтисе - Нуртдинов Хафиз Мөхәммәтдин улы (03.01.1908 – 05.05.1986)**



Хафиз, авыл малае, 14 яшендә туганнарына кунакка баргач, үз гомерендә беренче тапкыр паровоз күрә һәм тимер юлга, аның исенә һәм тавышына гомерлеккә гашыйк була. Хафиз әтисеннән аны шәһәргә машинистлыкка укырга җибәрүен сорый, әмма әтисе сүзеннән тайпылмый – өйдә эшче кирәк. 15 яшендә Хафиз шәһәргә качып китә һәм һөнәр училищесына укырга керә. Ул хезмәт юлын паровозда кочегар булып башлый. Тора-бара Хафиз паровозның машинисты булып эшли башлый. Сугыш вакытында бабаем поездда

фронткан танклар, азык-төлек ташый. Ул чын Каһарман, аның медальләре бик күп. Сугыштан соң Хафиз бабай заманча электровозлар йөртә, аннан соң Красноуфимск шәһәренең тимер юл станциясе җитәкчесе була. Пенсиягә чыккач, ул актив рәвештә сәяси темаларга лекцияләр белән чыгышлар ясый, газета һәм журналларга мәкаләләр яза. Ул шулай ук умартачылыкка укый, Урал таулары урманнарында аның бик күп умарталары була.

*Әбием Бәйрәмова Ә.Х. истәлекләреннән:*

*«Әти гел яңалыкка омтыла иде, максатка ирешүдә ихтыяры көчле иде.Ул үзенең балаларын укымышлы итеп күрергә теләде һәм безне югары белем алырга этәрде. Бабай үз балаларына, югары белем тормышта һәрвакыт кирәк булачак, дип әйтә торган булган. Ул балаларына үзенең хыялы турында сөйли торган булган, киләчәктә аның балалары укып чыгып, ата-ана йортында үз парлары, балалары (оныклары) белән бергә зур табынга җыелу булган аның хыялы».*

Шулай килеп чыга да. Барлык балалары да югары белем ала, төрле зур шәһәрләргә таралалар һәм үз гаиләләре, балалары белән бәйрәмнәрдә Советлар Союзының барлык почмакларыннан, һичшиксез, аталары йортына, табынга җыелалар.

**Нуртдинов Сталик (Станислав) Хафиз улы (12.01.1937-8.02.1982)**
(әбинең абыйсы)



Сталик балачактан ук сәләтле бала булып үсә. Өч яшендә инде кычкырып газеталар укыган, дүрт яшендә әтисе аны паровоз депосына эшенә үзе белән йөртә торган булган, ул анда зур абыйларны, Хафизның хезмәттәшләрен шахматта җиңә торган булган. Үсә төшкәч, әтисе үрнәгендә, Сталик хезмәт коллективлары алдында элек “агымдагы вакыт” дип аталган сәяси мәгълүматлар белән чыгыш ясаган. Ул бик яхшы укыган, мәктәпнең комсоргы булган. Мәктәптән соң Сталик Свердлау политехник институтының радиотехника факультетын тәмамлый. Институттан соң ул Түбән Новгород политехника институтына аспирантурага керә һәм кандидатлык диссертациясе яклый. Соңрак аны институтка укытырга чакыралар, анда ул доцент була, аны студентлар бик яратканнар һәм бер лекциясен дә калдырмаганнар. Сталик үзенең студентлары өчен палаткалар белән урманга сәяхәтләр оештыра, яшьләрнең иҗади потенциалын ача, шулай ук СТЕМ (студентлар миниатюр театры) белән җитәкчелек итә, трубада бик яхшы уйный.

1964нче елда Станислав Бөек Ватан Сугышы герое Виктор Колосовның кызы Светлананы очрата. Ярты елдан соң алар өйләнешәләр. Әлеге никахтан ике уллары туа: Илья (1965 елда туган) һәм Денис (1974нче елда туган).Ләкин, кызганычка каршы, Сталик Нуртдиновның гомер юлы иртә өзелә, моңа авыр хәрби балачагы һәм үз өстенә алган зур йөк йогынты ясый. 45 яшендә аның йөрәге кинәт тибүдән туктый, бу гаиләсе һәм политехника институты өчен зур югалту була.

**Әбием – Бәйрәмова (Нурдинова) Әнисә Хафиз кызы (1938нче елда туган)**



Әбием Уралда, Серов шәһәрендә туган. Ул Мәскәү китапханә институтын тәмамлый һәм билгеләнү буенча Казанга юнәлә. Ул биредә гомере буе Авиация сәнәгате өлкәсендә хезмәт куя. Хәзерге вакытта ул лаеклы ялда.

## 3. ГАИЛӘБЕЗНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ТАРИХЫ. БУЫННАР ДӘВАМЧАНЛЫГЫ.

Безнең нәселнең яшь вәкилләре белемгә омтыла, югары белем алалар һәм фәнни, иҗади зыялылар катламын тәшкил итәләр.

**Әтием – Бәйрәмов Илшат Рәкыйпь улы (1969нчы елда туган)**



Әти ике – техник һәм икътисадый – югары белем ала. Казан авиация институтының радиотехника факультетын тәмамлаганнан соң, әтием бабаем белән металлик торбаларны металларны тутыгудан саклауның электрохимик инновацион методын булдыру һәм кулланылышка кертүдә катнаша. Әлеге метод бүгенге көндә Татарстан Республикасында һәм бөтен Россия күләмендә киң кулланыла.

Серго Орджоникидзе исемендәге Дәүләт идарә университетының халыкара икътисады һәм Казан Дәүләт университетының икътисад факультетын тәмамлаганнан соң әтиемнең эше, өзлексез, шунын белән бәйле.

Минем әти бик яхшы икътисадчы, ул Атлант Лизинг, Вектор Лизинг, Промлизинг компанияләре эшчәнлеген җитәкләде. Лизинг Россия предприятиеләренә үсәргә булыша. Хәзерге вакытта да аның эшчәнлеге икътисад белән бәйле.

**Әнием – Бәйрәмова (Әхмәдиева) Ләйлә Нуровна (1971 нче елда туган)**



Әнием – табиб, медицина фәннәре кандидаты, невролог, остеопат, психолог, халыкара лектор, Дисциплинаара миофункциональ терапия ассоциациясенең (IAMPT) неврология һәм остеопатия буенча эксперты.

Әни – берничә медицина белгечлеген: остеопатия, неврология, нейрофизиология, стоматология, логопедия һәм психология өлкәләрен берләштереп эшләүче уникаль белгеч. Сөйләм формалашуы һәм теш-казналык бозылу проблемаларына дисциплинаара якын килү аңа әлеге проблеманы чишүдә өчкатлы алгоритм тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә.

Әнием – логопедлар һәм ортодонтлар эшендә яңа юнәлеш булдыручы – авыруларны предлогопедик һәм преортодонт әзерләү юнәлешен табучы да.

**Әниемнең энесе – Әхмәдиев Равил Нур улы ( 1976 нчы елда туган)**



1998 нче елда Әлмәт нефть институтын тәмамлый һәм Татнефть акционерлык җәмгыятенең Альметьевнефть НГДУга нефть тыгару операторы булып эшкә керә. Җитештерүгә рационаллаштыра торган берничә тәкъдим кертә. АҖ Татнефтьнең яшь белгечләр арасында үткәргән төрле конкурсларда җиңүче була. 2004 нче елда Казан Дәүләт Финанс-икътисад институтын тәмамлый. Гади эшчедән ПАО Татнефтьнең нефть һәм газ чыгару Департаментының нефть һәм газ чыгару идарәсе җитәкчесенә кадәр барлык баскычларны үтә.

Триатлон белән мавыга, әлеге спорт төрендә берничә тапкыр призерлар рәтендә була. Өйләнгән, хатыны белән дүрт ул тәрбиялиләр.

Безнең буын, кайда гына яшәвенә карамастан, татар тамырлары белән горурлана.

**Минем туганнан туган абыем Кучкильдин Рушан Хәбибҗан улы ( 1996 нчы елда туган)**




Минем туганнан туган абыем Себердән. Ул Курган өлкәсе Шатрау районы Кызылбай авылында туып үсә.

Аңа 6 яшь булганда аңа табиблар “3 нче дәрәҗәдәге сколиоз” диагнозы куялар һәм операция ясарга тәкъдим итәләр, юкса, бала гомер буена гарип булып калачак, диләр. Әти-әнисе операциядән баш тарта. Бердәнбер шансы спорт була. Рушан көн саен гимнастика белән шөгыльләнә башлый. Бер елдан соң табиб комиссиясе үтәргә баргач, табиблар шаккаталар: алар алдында бер дигән төз гәүдәле сау-сәламәт бала басып тора.

Шул мизгелдән алып Рушан спорт белән шөгыльләнүен дәвам итә һәм төрле яклап үсә. Армиядә хезмәт итеп кайта.

Бу аңа «ТАТАР ЕГЕТЕ. СЕБЕР ЙОЛДЫЗЫ 2017» конкурсында җиңүче булырга ярдәм итә.

**Апам – Бәйрәмова Энҗе Илшат кызы (1995 нче елда туган)**



Казанның 39нчы мәктәбен көмеш медальгә тәмамлый, хәзер Вена дәүләт университетында биолог һөнәренә укый.

Энҗе иҗтимагый тормышта бик актив. 2013 нче елда Венага килгәч, бергә укыган төркемдәшләре өчен үзлегеннән Дунайда Сабантуй үткәрә. 2015 нче елда Энҗе Рива Ханым Рюдиссер белән Австриядә татар җәмгыятен юридик яктан рәсмиләштерә һәм икенче елга ук ТР Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Венада беренче рәсми “Сабантуй-2016” үткәрелә.

2018 елда ул Будапештта “Ауропа кызы” матурлык конкурсында җиңә һәм Казанда “Татар кызы-2018” конкурсында катнаша.








2019 елда Энҗене яшьләр арасында Аурупа татар альянсы Председателе Киңәшчесе итеп сайлыйлар. Энҗе татар мәдәниятен саклау өчен бик күп көч куя.

**Мин – Бәйрәмов Искәндәр Илшат улы (2005 елда туганмын)**



Мин дә 39нчы мәктәпнең 8нче «Г» сыйныфында укыйм. Минем гаиләмнең Россия тарихына керткән өлеше безнең тарафтан да дәвам иттерелер. Моңа мин үземнең шигыремне багышладым:

Йолдызлар егылсын, әйдә,
Чынга ашсын хыяллар...
“Мин бит сезне яратам!”
Дип әйтә юлламалар.
Хыяллар чынга ашсыннар,
НЛОга ышансыннар, әйдә,
Тормышта син ни эшләдең,
Син ни эшләдең? Ни өчен...?

**ГАИЛӘНЕҢ ТАМЫРЛАНГАН ТРАДИЦИЯЛӘРЕ**

Әниемнең истәлекләре буенча – барлык туганнар Гариф бабай йортында еш җыела торган булган. Нинди дә булса эш эшләү өчен: бергәләп өй салу, бәрәңге алу, печән чабу, Сабантуйга җыелу кебек матур традицияләр булган. Эштән соң зур гаилә табын янына җыелган, Гариф бабай төрле кызыклы вакыйгалар сөйләгән, җырлап та җибәргән:

«Суда, суда,
Суда йөзәләсеңме?
Мин сине күрми түзәлмим!
Ә син түзәләсеңме?»

Төп йортка зур табыннар артына җыелу безнең көннәргә кадәр килеп җиткән, хәзер аны “Әсәйдә җыен” дип атап йөртәбез. Июль аеның беренче якшәмбесендә Татарстанның Азнакай районы Әсәй авылында безнең нәсел буыннарының вәкилләре җыела. Һәр очрашу – чын бәйрәм төсен ала. Табигатьтә урманда зур табын корыла, аның артында җыйналып утырабыз. Зурлар да, балалар да сәнгатьле итеп шигырьләр сөйли, җырлар җырлый.



*«Әсәйдә җыен», июль 2019 ел.*

Яшь буын нәсел тарихын саклап калырга омтыла. 2018 нче елда Гөлсинә Теплова (Шаһиева) мәгълүматлар туплап, “Буыннар хәтере. Шаһиевлар һәм Әхмәдиевлар токымы истәлекләре. (XIX гасыр ахыры - XXI гасыр башы)” дип аталган китап яза.






Китапны яшь буынга тапшырабыз. Бездән соң дәвам итәрләр, нәсел җебен өзмәсләр, дип ышанабыз.

Дорогой внук, вручаем тебе эти записи и очень надеемся, что они будут тебе интересны, продолжены тобой и связь поколений не прервется.

Россия
Республика Татарстан
Азнакаево – Набережные Челны
2018

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, пер

54

*«Һәркем үз канында һәм нерв күзәнәкләрендә борынгы әби-бабалары нәрсә уйлаган, нәрсәгә дулкынланган - барысы турында хәтер йөртә. Күңел ул борынгы әби-балararыбызның меңтавыштан торган хоры гына. Һәм һәрберебез, үзе дә моны сизмәстән, шәхес буларак түгел, ә токым буларак эш йөртә!" – дип язган Михаил Осип улы Меньшиков. (1859-1918)* [11].

Һәм мин безгә борынгы әби-бабаларыбыз калдырган мирасны кабул итеп алам. Һәм «Җиденче буын бабаларымның амәнәтен кабул итеп алам»! [9]

## 3. НӘТИҖӘЛӘР.

**1 Нәселебез үз башлангычларын авылдан ала. Безнең борынгы әби-бабаларыбыз авыл кешеләре булган. Ул заманда авыл хуҗалыгы илнең икътисадый терәге булган һәм безнең нәсел вәкилләре Россиянең муллыгын арттыралар.**

**2. Бөек Ватан Сугышы башлангач, безнең нәселнең ир-атлары фронтка китә, анда Ватанны саклау өчен аяусыз көрәшәләр. Нәселнең хатын-кызлары исә тылда хезмәт куя, шул рәвешле, безнең нәсел Бөек Ватан Сугышында җиңеп чыгуда да үзеннән өлеш кертә.**

**3. Тыныч вакытлар килгәч, безнең нәселнең яшь әһелләре белем алырга омтыла, шәһәргә киләләр, югары белем алалар һәм фәнни, иҗади зыялылар катламын тәшкил итәләр.**

**4. Безнең нәсел тарихы Россия үсеше белән тыгыз бәйләнгән.**

**5. Минем нәселем Россия тарихына саллы өлеш керткән.**

## 4. КУЛЛАНЫЛГАН ЧЫГАНАКЛАР ИСЕМЛЕГЕ.


1. Курган өлкәсе Шатрау районы Кызылбай авыл советы архивы.
2. Татарстан Республикасы Азнакай районы Әсәй авыл советы архивы.
3. Гариф Әхмәдиев истәлекләре.
4. Теплова Гөлсинә “Буыннар хәтере. Шаһиевлар һәм Әхмәдиевлар нәселе истәлекләре. (XIX гасыр ахыры - XXI гасыр башы)» Россия. Татарстан Республикасы, Азнакай-Яр Чаллы, 2018 ел.
5. Әхмәдиевлар нәселенең тарихчы Дамир Гарифуллин тарафыннан төзелгән шәҗәрәсе.
6. Россия тарихы. 20 гасыр. Гомуми белем бирү учреждениеләренең 9нчы сыйныфы өчен дәреслек. М. “Мәгариф”, 2000 ел.
7. Кречетов П. И. Орлов губериясен тасвирлау өчен материаллар. Рига. 1905 ел.
8. Интернет материаллары.
9. Әхмәдиев Н. Г. ”Күзгә күз”, шигырьләр җыентыгы.
10. Зур Россия энциклопедиясе, 4 том, М. “БРЭ” фәнни нәшрияты. 2006 ел.
11. Меньшиков М. О. «Рус милләтеннән хатлар».
12. «Бөекләр, танылганнар, талантлылар…» http://family.tgim1.edusite.ru/p6aa1.html
13. Шагыйрь Нур Әхмәдиев – Азнакай горурлыгы.
14. ИА "Татар-информ", 14 декабря 2016 http://aznakaevo-rt.ru/news/date/list/2016-12-14%2015:14:49
15. Татар электрон китапханәсе http://kitap.net.ru/ahmadiev.php
16. «Нур Әхмәдиев: Тормышта һәрвакыт могҗизага урын бар!» «Казан Хәбәрләре» газетасында мәкалә https://kazved.ru/news/society/29-12-2016/nur-ahmadiev-v-zhizni-vsegda-est-mesto-chudu-4683522